**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АПАС ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

2020 ел,1 октябрь № 5

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының “Апас шәһәр тибындагы поселогы” муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү турындагы карарына үзгәрешләр кертү турында**

“Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләүләре күләмнәрен арттыру турында" Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 658 номерлы карарына таянып, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Апас шәһәр җирлеге Советы карар бирә:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Апас шәһәр җирлеге Советының 2018 елның 5 апрелендәге 109 номерлы "Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы "Апас шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү турында" гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итергә:

“2. Муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләме авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладына карата бермәбер исәпләнә. Шул ук вакытта авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладының күләме 11 498 сум тәшкил итә.”.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2020 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

**“Апас шәһәр тибындагы поселогы”**
**муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары Н.Т. Исмәгыйлев**